ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 565-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 565-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2490-VI ДС

565 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяда:

а) 4 пунктның икенче җөмләсендә «Сайланулы вазыйфаи затлар,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе сенаторлары,» сүзләрен өстәргә, «әгъзалары» сүзеннән соң «, чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

б) $7^1$ пунктта «исемлеген» сүзеннән соң «кәгазь чыганакта һәм (яисә) машинада укырлык рәвештә Татарстан Республикасы Үзәк Сайлау комиссиясе билгеләгән рәвешләрдә һәм тәртиптә» сүзләрен өстәргә, «атасының исеме,» сүзләреннән соң «туган көне, граждан паспорты яисә паспортны алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм бирелү датасы,» сүзләрен өстәргә;

в) $11^2$ пунктта «өч көннән» сүзләрен «җиде көннән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 пунктта «, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакырулары булганда, алар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләрен «, федераль законнарда каралган дәүләт органнары чакыруы булганда, алар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 32 статьяның 3 пунктында «, шулай ук тавыш бирү көнендә» сүзләрен «һәм тавыш бирү көнендә (тавыш бирүнең соңгы көнендә) референдум округы территориясендә тавыш бирү тәмамланган мизгелгә кадәр» сүзләрен өстәргә;

3) 44 статьяның 5 пунктындагы «о» пунктчасында «, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «Россия юридик затлары» сүзләреннән соң «, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

4) 49 статьяның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Тавыш бирү көнендә (референдумда тавыш бирүнең соңгы көнендә) тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң комиссияләрдәге файдаланылмыйча калган бюллетеньнәр санала һәм әлеге Законның 53 статьясындагы 3 пункты нигезендә юкка чыгарыла. Барлык комиссияләрдә, участок комиссияләреннән тыш, файдаланылмый калган бюллетеньнәрне юкка чыгарганда акт төзелә, анда юкка чыгарылган бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә. Бюллетеньнәрне юкка чыгарганда әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар катнашырга хокуклы. Бу бюллетеньнәр комиссиянең башка документациясе белән бергә комиссия секретаренда саклана.»;

5) 50 статьяда:

а) 9 пунктта «бозылган бюллетень» сүзләреннән соң «әлеге законның 53 статьясындагы 3 пункты таләпләре нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 12 пунктта «шунда ук читләштерелә» сүзләреннән соң «һәм тавыш бирү бинасыннан чыгарыла» сүзләрен өстәргә;

в) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Референдум округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6) 51 статьяның 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Референдум округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы референдумда катнашучыларның референдум үткәргәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

7) 53 статьяның 3 пунктында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар катнашында файдаланылмаган бюллетеньнәрне саныйлар һәм, референдумда катнашучы тамгасы куелыр өчен

каралган квадратларны бозмыйча, мондый бюллетеньнәрне аларны алга таба файдалану мөмкинлеген бетерә торган Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән ысуллар белән бозып, юкка чыгаралар, аннары бозылган файдаланылмаган бюллетеньнәрнең санын, шулай ук тавыш бирүне уздырганда референдумда катнашучылар тарафыннан бозылган бюллетеньнәрнең санын игълан итәләр һәм аларны тавыш бирү бинасындагы тавыш бирү йомгаклары турында киңәйтелгән беркетмәнең 5 юлына язып куялар.».

**2 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяда:

а) 4 пунктның икенче җөмләсендә «Сайланулы вазыйфаи затлар,» сүзеннән соң «Россия Федерациясе сенаторлары,» сүзләрен өстәргә, «әгъзалары» сүзеннән соң «, чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

б) $7^1$ пунктта «исемлеген» сүзеннән соң «кәгазь чыганакта һәм (яисә) машинада укырлык рәвештә референдум оештыручы комиссия билгеләгән рәвешләрдә һәм тәртиптә» сүзләрен өстәргә, «атасының исеме,» сүзләреннән соң «туган көне, граждан паспорты яисә паспортны алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм бирелү датасы,» сүзләрен өстәргә;

в) $11^2$ пунктта «өч көннән» сүзләрен «җиде көннән» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 пунктта «, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, территория комиссиясенең чакыруы булганда, алар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләрен «, федераль законнарда каралган дәүләт органнары чакыруы булганда, алар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 34 статьяның 3 пунктында «, шулай ук тавыш бирү көнендә» сүзләрен «һәм тавыш бирү көнендә (тавыш бирүнең соңгы көнендә) референдум округы территориясендә тавыш бирү тәмамланган мизгелгә кадәр» сүзләрен өстәргә;

3) 46 статьяның 5 пунктындагы «о» пунктчасында «, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә

катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

4) 51 статьяның 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Тавыш бирү көнендә (референдумда тавыш бирүнең соңгы көнендә) тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң комиссияләрдәге файдаланылмыйча калган бюллетеньнәр санала һәм әлеге Законның 55 статьясындагы 3 пункты нигезендә юкка чыгарыла. Барлык комиссияләрдә, участок комиссияләреннән тыш, файдаланылмый калган бюллетеньнәрне юкка чыгарганда акт төзелә, анда юкка чыгарылган бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә. Бюллетеньнәрне юкка чыгарганда әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән затлар катнашырга хокуклы. Бу бюллетеньнәр комиссиянең башка документациясе белән бергә комиссия секретаренда саклана.»;

5) 52 статьяда:

а) 9 пунктта «бозылган бюллетень» сүзләреннән соң «әлеге законның 55 статьясындагы 3 пункты таләпләре нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 12 пунктта «шунда ук читләштерелә» сүзләреннән соң «һәм тавыш бирү бинасыннан чыгарыла» сүзләрен өстәргә;

6) 55 статьяның 3 пунктында беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затлар катнашында файдаланылмаган бюллетеньнәрне саныйлар һәм, референдумда катнашучы тамгасы куелыр өчен каралган квадратларны бозмыйча, мондый бюллетеньнәрне аларны алга таба файдалану мөмкинлеген бетерә торган Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән ысуллар белән бозып, юкка чыгаралар, аннары бозылган файдаланылмаган бюллетеньнәрнең санын, шулай ук тавыш бирүне уздырганда референдумда катнашучылар тарафыннан бозылган бюллетеньнәрнең санын игълан итәләр һәм аларны тавыш бирү бинасындагы тавыш бирү йомгаклары турында киңәйтелгән беркетмәнең 7 юлына язып куялар.».

**3 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяда:

а) $7^1$ өлештә «законнарны бозган өчен» сүзләрен «законнарны бозган һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

«$7^2$. Тиешле карар кабул ителгәнче җибәрелә торган комиссиянең күрсәтмәсе, комиссия әгъзаларын билгеләп куючы органның гарызнамәсе буенча юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы, аның территориаль органнары комиссияләр әгъзалары итеп билгеләп куела торган затларга карата тикшерү үткәрә һәм алар буенча, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына алар хакындагы белешмәләрнең кертелүен күрсәтеп, мәгълүмат бирә.»;

2) 18 статьяда:

а) 1 өлештә:

4 пунктта «дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары» сүзләрен «Россия Федерациясе сенаторлары, дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «законнарны бозган өчен» сүзләрен «законнарны бозган яисә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «, шулай ук экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

б) 6 өлешнең беренче абзацында «үзен билгеләп куйган» сүзләрен «компетенциясенә комиссиянең әлеге әгъзасын билгеләп кую караган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлештә:

2 пунктта «законнарны бозган өчен» сүзләрен «законнарны бозган яисә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар өчен» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «йә экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзе хакында белешмәләр кертелгәндә» сүзләрен өстәргә;

3) 22 статьяда:

а) 2 өлештә «Сайланулы вазыйфаи затлар,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе сенаторлары,» сүзләрен өстәргә, «вәкаләтләре туктатып торылган әгъзаларыннан тыш,» сүзләреннән соң «чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган

затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

б) 3[1] өлештә «сайлаулар әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы комиссиягә» сүзләреннән соң «сайлауларны оештыручы комиссия тарафыннан билгеләнгән рәвешләрдә һәм тәртиптә кәгазьдә һәм (яисә) машинадан укыла торган рәвештә» сүзләрен өстәргә, «һәр күзәтүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме,» сүзләреннән соң «туган көне, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясе, номеры һәм аның бирелү датасы,» сүзләрен өстәргә»;

в) 8 өлештә «дәүләт хакимияте органнарының, сайлауларны оештыручы комиссияләрнең чакыруы булганда Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләрен «федераль законда каралган дәүләт органнарының чакыруы булганда Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр» сүзләренә алмаштырырга;

4) 23 статьяның 3 өлешендә «өч көннән дә» сүзләрен «җиде көннән дә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 33 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. Чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар кандидатларның һәм сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре була алмый.»;

6) 39 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5[1] өлеш өстәргә:

«5[1]. Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органнарына депутатларны сайлауларны уздырганда кандидат кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына чит ил агенты статусын туктатырга тиеш.»;

7) 40 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 3[4] өлеш өстәргә:

«3[4]. Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органнарына депутатларны сайлауларны уздырганда кандидат кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына чит ил агенты статусын туктатырга тиеш.»;

б) 5[1] өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Сайлау комиссиясенә аерым кандидатка карата тапшырылган тиешле бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округында күрсәтелгән гражданны дөрес билгеләргә мөмкинлек бирми торган документларны әзерләүдә җибәрелгән хаталар (өстәп язулар) тиешле кандидатны, ул танылканганчыга кадәр, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча кандидатлар исемлегеннән төшереп калдыру өчен нигез булып тора.»;

8) 41 статьяга түбәндәге эчтәлекле 1[4] өлеш өстәргә:

«$1^4$. Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органнарына депутатларны сайлауларны уздырганда кандидат кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына чит ил агенты статусын туктатырга тиеш.»;

9) 42 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^3$ өлеш өстәргә:

«$2^3$. Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органнарына депутатларны сайлауларны уздырганда кандидат кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына чит ил агенты статусын туктатырга тиеш.»;

10) 45 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Әгәр тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалык бирү турындагы гаризада кандидатның чит ил агенты булуы турында белешмәләр күрсәтелгән булса, кандидат кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәүне гамәлгә ашыручы сайлау комиссиясенә кандидатны теркәү өчен кирәкле башка документлар белән бергә коммерциягә карамаган оешмаларны теркәү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органының кандидатны чит ил агентлары реестрыннан төшереп калдыру турындагы хәбәрнамәсен йә судның тиешле карарын тапшыра.»;

11) 46 статьяның $4^1$ өлешенә «Федераль законда билгеләнгән нигезләр буенча» сүзләреннән соң «, шулай ук кандидат тарафыннан әлеге Кодексның 39 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты нигезендә тапшырыла торган белешмәләр составында аның Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары (кертемнәре), акчалары һәм кыйммәтле әйберләре һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булуы турында белешмәләр күрсәтелгән очракта йә әлеге статьяның $4^3$ - $4^7$ өлешләре нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә күрсәтелгән белешмәләр ачыкланган очракта» сүзләрен өстәргә;

12) 47 статьяда:

а) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $1^3$ пункт өстәргә:

«$1^3$) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны уздырганда – кандидатның әлеге Кодексның 39 статьясындагы $5^1$ өлешендә, 40 статьясындагы $3^4$ өлешендә, 41 статьясындагы $1^4$ өлешендә һәм 42 статьясындагы $2^3$ өлешендә билгеләнгән таләпләрне үтәмәве;»;

б) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $3^2$ пункт өстәргә:

«$3^2$) Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда – кандидатның әлеге Кодексның 40 статьясындагы $3^4$ өлешендә билгеләнгән таләпләрне үтәмәве;»;

13) 52 статьяның 3 өлешендә «сайлау комиссияләре аппаратлары хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар

турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

14) 56 статьяның 3 өлешендә «, шулай ук тавыш бирү көнендә» сүзләрен «һәм тавыш бирү көнендә (тавыш бирүнең соңгы көнендә) сайлау округы территориясендә тавыш бирү тәмамланган вакытка кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

15) 61 статьяның $4^1$ өлешендә «чит ил агенты булып торучы теркәлгән кандидат йә» сүзләрен төшереп калдырырга, «чит ил агенты йә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат» сүзләрен «кандидат йә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидат» сүзләренә алмаштырырга, «чит ил агенты йә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидатны» сүзләрен «кандидатны йә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән кандидатны» сүзләренә алмаштырырга;

16) 62 статьяның 12 өлешендә «чит ил агенты булган кандидат,» сүзләрен һәм «чит ил агенты йә» сүзләрен төшереп калдырырга;

17) 67 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда сайлау фондлары акчаларын тотуның кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәгәнче гамәлгә ашырылырга мөмкин булган иң чик күләме әлеге Кодексның 89 статьясындагы 4 һәм 6 өлешләрендә, $104^6$ статьясындагы 4 өлешендә, 106 статьясындагы 4 һәм 6 өлешләрендә билгеләнгән сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләменең 30 процентын тәшкил итә.»;

б) 14 өлешнең 14 пунктында «шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга, «Россия юридик затлары» сүзләреннән соң «экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар» сүзләрен өстәргә;

18) 72 статьяның 5 өлешендәге 6 пунктына «һәм кандидатларның, сайлау берләшмәләренең финанс хисапларын тапшыру һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлау комиссиясенә тиешле чаралар күрү һәм гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен хокук саклау органнарына һәм башка органнарга тиешле материаллар җибәрү турында тәкъдимнәр тапшыра» сүзләрен өстәргә;

19) 73 статьяның 4 өлешендә «чит ил агенты йә» сүзләрен төшереп калдырырга;

20) 75 статьяда:

а) $10^1$ өлештә «чит ил агенты йә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 22 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Тавыш бирү көнендә (тиешле сайлауларда тавыш бирүнең соңгы көне) тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң комиссияләрдәге файдаланылмаган бюллетеньнәр әлеге Кодексның 79 статьясындагы 3 өлеше таләпләре нигезендә санала һәм юкка чыгарыла. Барлык комиссияләрдә, участок комиссияләреннән тыш, файдаланылмаган бюллетеньнәрне юкка чыгарганда акт төзелә, анда юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны күрсәтелә. Бюллетеньнәрне юкка чыгарганда әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар катнашырга хокуклы. Бу бюллетеньнәр комиссия секретаре тарафыннан комиссиянең башка документациясе белән бергә саклана.»;

21) 76 статьяда:

а) 12 өлештә «шуннан соң» сүзләреннән соң «әлеге Кодексның 79 статьясындагы 3 өлеше таләпләре нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 15 өлештә «шунда ук читләштерелә» сүзләреннән соң «һәм тавыш бирү бинасыннан чыгарыла» сүзләрен өстәргә;

в) 19 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә билгеләнгән дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

22) $76^1$ статьяның 17 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Тиешле сайлау округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә билгеләнгән дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә вакытыннан алда тавыш бирүе, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.»;

23) 77 статьяның 19 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Тиешле сайлау округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы сайлаучыларның әлеге Кодексның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган тавыш бирү көненә билгеләнгән дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар үткәрелгәндә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүе, әлеге Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

24) 79 статьяның 3 өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң участок комиссиясенең хәлиткеч

тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар катнашында файдаланылмаган бюллетеньнәрне саныйлар һәм, сайлаучы тамгасын кую өчен билгеләнгән квадратларны бозмыйча, мондый бюллетеньнәрне Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән ысуллар белән алга таба куллану мөмкинлеген юкка чыгарып, аларга зыян салып юкка чыгаралар, шуннан соң файдаланылмыйча юкка чыгарылган бюллетеньнәр, шулай ук тавыш бирүне уздырганда сайлаучылар тарафыннан бозылган бюллетеньнәр санын игълан итәләр һәм аларны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның тавыш бирү бинасындагы зурайтылган рәвешенең 5 юлына язып куялар.»;

25) 87 статьяның 3 өлешендә «88 статьясындагы 4 өлешендә каралган» сүзләрен «94 статьясындагы 1 өлешенең 24 пунктында каралган» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә әзерләнгән.

Закон проектының максаты – Татарстан Республикасы Сайлау кодексын һәм 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы референдумы турында», 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы законнарын күрсәтелгән Федераль законга туры китерү.

Закон проектында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә кандидат кандидатны, кандидатлар исемлекләрен теркәү өчен кирәкле документлар бирү вакытына чит ил агенты статусын туктатырга тиеш. Күрсәтелгән таләпне үтәмәү кандидатны теркәмәү, кандидатны таныкланган кандидатлар исемлегеннән төшереп калдыру өчен нигез булып тора. Чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар, экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затлар кандидатларның һәм сайлау берләшмәләренең вәкаләтле вәкилләре, шулай ук күзәтүчеләр була алмый. Экстремистлык яисә террорчылык оешмасы эшчәнлегенә катнашы булган затлар турында бердәм белешмәләр реестрына үзләре хакында белешмәләр кертелгән затларга сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары булу, шулай ук кандидатларның, теркәлгән кандидатларның, сайлау берләшмәләренең сайлау фондларына, референдум фондларына акчалар кертү тыела.

Закон проектында кандидатларны теркәгәнче сайлау фондлары акчаларын тоту мөмкинлеге карала. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда кандидатны теркәгәнче чыгымнар суммасы законда билгеләнгән сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләменең 30 процентын тәшкил итәргә мөмкин.

Закон проектында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен аккредитация узуга гариза бирү срогы (тавыш бирү (вакытыннан алда тавыш бирү) көненә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча), шулай ук тиешле сайлау округыннан читтә булган шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарындагы затларның тавыш бирү тәртибе төгәлләштерелә.

Аларның тавыш бирүе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Моннан тыш, закон проекты 67-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы $14^2$ пунктын сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә ачыкланган хаталар (ялгыш язулар) кандидатлар исемлегенә кертелгән башка кандидатларны билгеләүгә каршы килмәгән очракта мондый исемлекне таныклаудан баш тарту йөкләнә торган өлештә Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми дип таныган Россия Федерациясе Конституция судының 2023 елның 7 июнендәге 31-П номерлы карарын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм (яисә) башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.